ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

МЕНДЕЛЕЕВ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУРАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

2021 елның 10 нчы ноябрендәге 44 нче номерлы **КАРАРЫ**

"Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегендә бюджет процессы турында"гы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Советының 2020 нче елның 24 нче гыйнварендәге 109 нчы номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлегендә бюджет процессы турында "гы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 15 статьясындагы 12 пунктының 2 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының бюджетка керүенең тулылыгын һәм үз вакытында керүен, бюджетның бердәм счетындагы калдыклар белән идарә итү операцияләреннән тыш, тикшереп торуны гамәлгә ашыра;

1.2. Нигезләмәнең 35 статьясындагы 27 пунктына түбәндәге эчтәлекле тәкъдим өстәргә: "кредит (займ) буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүче муниципаль гарантия кредит килешүендә (займ килешүендә) һәм (яисә) күрсәтелгән муниципаль гарантияне бирү турындагы шартнамәдә кредитор (заемчы) йөкләмәләрен үз ягыннан күрсәтелгән кредит (займ) акчаларының максатчан кулланылышын тикшереп тору шарты белән бирелә.";

1.3. Нигезләмәнең 13 статьясындагы 3 пунктының 5 пунктчасына "Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш"сүзләрен өстәргә;

1.4. Нигезләмәнең 13 статьясындагы 2 пунктының 4 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4) Россия Федерациясе керемнәре чыганаклары исемлегенә һәм бюджет керемнәре чыганаклары реестрына кертү өчен аларга беркетелгән керемнәр чыганаклары турында белешмәләр тапшыра;"\

чыганаклары турында белешмәләр тапшыра;";

1.5. Нигезләмәнең 41 статьясындагы 1 өлешенә:
1) түбәндәге эчтәлекле өченче абзац өстәргә::
- Россия Федерациясенең милли үсеш максатларын һәм аларга ирешү буенча хакимият органнары эшчәнлегенең юнәлешләрен билгели торган документлар;";

2) өченче – дүртенче абзацларны дүртенче – бишенче абзацлар дип санарга.

2. Әлеге карарны Турай авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмати стендларда урнаштырып таныштырырга, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында Турай авыл җирлеге бүлегендә www.mendeleevsk.tatar.ru, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru  урнаштырырга
3. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Турай авыл  җирлеге  Советы  рәисе                          А.М.Рәхимова